КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1367

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 февраль, 55 нче карары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Эвакуация комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.Ю.Авандеевны, Э.Л.Борһановны, Р.Т.Гатауллинаны, А.А.Сурдаковны, Г.Т.Хисаметдинованы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оештыру эшләре бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру оештыру төркеме башлыгы Булат Фердинанд улы Әскәровны;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының төбәкара элемтәләрне үстерү бүлеге башлыгы – матди кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме башлыгы Дмитрий Евгеньевич Будкинны;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының элемтә хезмәтләрен үстерү бүлеге 1 разрядлы өлкән белгече – хәбәр итү һәм элемтә төркеме башлыгы Андрей Николаевич Макаровны;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының эшләр идарәчесе – комиссия әгъзасы Андрей Иванович Рюховны;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының инфраструктура тәэмин ителеше һәм иҗади индустрияләр бүлеге башлыгы – мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләү төркеме башлыгы Виктория Владимировна Самсонованы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин